ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.04.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1006**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган (2019 елның 28 декабрендәге 2587 номерлы, 2021елның 2 февралендәге №141 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 999 номерлы карарына ярашлы рәвештә, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган (2019 елның 28 декабрендәге 2587 номерлы, 2021елның 2 февралендәге №141 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Гаиләнең җан башына уртача керем компенсация алу хокукын билгеләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның

20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган, балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең бер кешегә уртача исәпләнгән керемен исәпләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 1174 номерлы карары белән кабул ителгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Балага айлык түләү билгеләгәндә гаиләнең уртача җан башына кереме гаилә әгъзаларының балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.

Аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә балага айлык пособиене алучының ире (хатыны) булган гражданнар керемнәре исәпкә алына.

Исәп-хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме уртача айлык җыелма керемне гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Исәп-хисап чорында гаиләнең уртача айлык җыелма кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез була.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык кереме хисап чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын әлеге керемнәре булган хисап чоры айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З.Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев